ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2020 Олы Кайбыч авылы № 542

«Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау мәсьәләләрендә хокук нормаларын куллануның киң чикләрен яисә нигезләнмәвен билгели торган коррупциоген факторларны төшереп калдыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктта «резерв фонд буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны төшереп калдырырга;

1 нче кушымтада:

4 пунктның 10 абзацында «-20 мең сум күләмендә» сүзләрен төшереп калдырырга ;

4 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- стихияле бәла-казалар, янгыннар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү;»;

4 пунктның 12-16,20 абзацларын төшереп калдырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслауга акчалар бүлеп бирү физик яисә юридик затның Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгате нигезендә гамәлгә ашырыла.

Физик һәм юридик затлар, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгате белән бергә, Башкарма комитет Җитәкчесенә күрсәтелгән максатларга чыгымнарның зарурлыгын, кичектергесезлеген һәм алдан күздә тотылмаганлыгын раслый торган документларны (шул исәптән органнарның китерелгән зыян турындагы белешмәләре, смета-финанс хисапларын, калькуляцияне, өстәмә чыгымнарны, счет-фактураны һәм проект-смета документациясен кертеп, таләп ителә торган күләмне нигезли торган акча күләме) тапшыра.

Матди ярдәм алуга, әлеге нигезләмәнең 4 пунктындагы 9-11, 18-19 абзацларында каралган очраклардан тыш, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган физик һәм юридик затлар хокуклы.»;

6 пунктны 2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип санарга;

10 пунктта «, шулай ук кирәк булган очракта – комиссия, экспертлар бәяләмәсе h.б.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3 Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина